**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районы**
**Арча муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәре**
**Башкарма комитеты**
**422000, ТР, Арча ш., мәйдан Советы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-12-35**

**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районы**
**Арча муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәре**
**Башкарма комитеты**
**422000, ТР, Арча ш., мәйдан Советы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-12-35**

# КАРАР

**«06» февраль 2023 ел** **№ 19**

**«Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын жыю тәртибе турында» Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитетының 23.12.2022 № 202 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнар жыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Арча шәһәр Советының 17.08.2022 № 74 карары нигезендә, 28.11.2022 №1, 29.11.2022 №2, 29.11.2022 №3, 29.11.2022 №4, 30.11.2022 №5, 30.11.2022 №6 жыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында, Арча шәһәре башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салымы чараларын жыю тәртибе турында» Арча шәһәре башкарма комитетының 23.12.2022 № 202 карары белән расланган Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын жыю тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 һәм 4 пунктларны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм түбәндәге адреслар буенча гражданнар күпләп жыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә: РТ, Арча районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт; Арча шәһәре, Совет мәйданы, 25 йорт, Арча шәһәре, Х.Такташ ур., 58 йорт; Арча шәһәре,

Кленовая ур., 4 йорт; Арча шәһәре, Банковская ур., 2а йорты.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Арча шәһәре башкарма
комитеты җитәкчесе Р.Ф.Касыймов